Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче Сәмәкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче Сәмәкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле билгеләнештәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (күперне ремонтлау, елга аша җәяүлеләр күпере төзү һәм урнаштыру, материаллар сатып алу) ;

-торак пункт территориясен төзекләндерү җәяүлеләр күпере территориясен төзекләндерү - туфрак кертү, җәяүлеләр күпере подъездына юлны тигезләү);».

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 28 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле билгеләнештәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау(күперне ремонтлау, елга аша җәяүлеләр күпере төзү һәм урнаштыру, материаллар сатып алу) ;

-торак пункт территориясен төзекләндерү җәяүлеләр күпере территориясен төзекләндерү - туфрак кертү, җәяүлеләр күпере подъездына юлны тигезләү);».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Сәмәкәй авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов